**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**20.12.2024 ел** **№ 93**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Советының 2024 елның 1 июлендәге 85 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Советының 2024 елның 01 июлендәге 85 номерлы «Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 5 һәм 6 пунктчаларын, 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/и җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге
Советы рәисе Ә.Ф.Сафиуллина